Республика Татарстан

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЛЯКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА

ул. Школьная , д. 1, с. Ляки
423367
Телефон: 4-66-16

Татарстан Республикасы

САРМАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЛӘКЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Мәктәп урамы, йорт 41, Ләке авылы 423366
Телефон: 4-66-16

ОКПО 93068387 ОГРН 1061687003036 ИНН/КПП 1636005542/163601001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**«20» август 2015 ел**

**КАРАР**
**№5**

2015 елга Ләке авыл җирлеге башкарма комитетының наркотик чараларның, психотроп матдәләрнең һәм прекурсорларның законсыз әйләнешенә бәйле җинаятьләрне һәм хокук бозуларны профилактикалау һәм кисәтү чаралары планын раслау турында.

"Наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр турында" 08.08.1988 ел, № 3-ФЗ Федераль законның 7 статьясындагы 2 өлеше, 2020 елга кадәр Россия Федерациясенең наркотикларга каршы дәүләт сәясәте стратегиясенең 9 пунктының "з " пунктчасы, Россия Федерациясе Президентының 2010 елның 9 июнендәге 690 номерлы Указы нигезендә Ләке авыл җирлеге башкарма комитеты карар итте:

1. 2015 елга Ләке авыл җирлеге башкарма комитетының наркотик чараларның, психотроп матдәләрнең һәм прекурсорларның законсыз әйләнешенә бәйле җинаятьләрне һәм хокук бозуларны профилактикалау һәм кисәтү буенча чаралар планын расларга.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» урнаштырырга (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Сарман муниципаль районы сайтында.

3.Әлеге карарның үтәлешен үзем контрольдә тотам.

Сарман муниципаль районы
Ләке авыл җирлеге
башкарма комитет җитәкчесе В. А. Афанасьев

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Ләке авыл җирлеге
Башкарма комитеты
" 20 " август 2015ел № 5
карарына кушымта

Ләке авыл җирлеге башкарма комитетының наркотик матдәләр, психотроп матдәләр һәм прекурсорларның законсыз әйләнешенә бәйле җинаятьләрне һәм хокук бозуларны профилактикалау һәм кисәтү буенча 2015 елга чаралар планы.

| № п/п | Чара исеме | Үтәү сроклары | Башкаручылар |
|---|---|---|---|
| 1 | Полициянең участок уполномоченные, Россия Эчке эшләр министрлыгының Сарман районы буенча бүлеге каршындагы Балигъ булмаганнар эшләре инспекторлары, җирле профилактика органнары белән балигъ булмаганнарны эшкә урнаштыру, хокук бозуга сәләтле затларны ачыклау, имин булмаган гаиләләр белән хезмәттәшлекне гамәлгә ашыру | даими | Ләке авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе, Башкарма комитет секретаре |
| 2 | Хокук бозуга сәләтле затлар белән шәхси әңгәмәләр уздыру | даими | Ләке авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе, Башкарма комитет секретаре , Россия Эчке эшләр министрлыгының Сарман районы буенча бүлегенең полиция участок уполномоченные (килештерү буенча) |
| 3 | Мәдәният учреждениеләренә (клубларга) спектакльләр, концертлар, башка театр-тамаша һәм күргәзмә чараларын үткәрүдә, халыкның төрле | даими | Ләке авыл җирлеге җирле үзидарә органнары |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | төркемнәренең ялын оештыруда, башка төр мәдәни - иҗади, мәдәни - танып белү, ял һәм башка эшчәнлекләрне тормышка ашыруда булышлык күрсәтү | | |
| 4 | Халык бәйрәмнәрен оештыруда катнашу | халык бәйрәмнәрен вакытында үткәрүне тәэмин итүче срокларда | Ләке авыл җирлеге җирле үзидарә органнары |
| 5 | Иҗтимагый оешмаларның җәмәгать тәртибен саклауны тәэмин итү, Физик культура һәм спортны үстерү мәсьәләләре буенча эшчәнлегенә ярдәм итү | даими | Ләке авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе |
| 6 | Алкоголизм һәм наркоманиядән интегүчеләр белән аңлату характерындагы шәхси әңгәмәләр уздыру | даими | Ләке авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе, Башкарма комитет секретаре, "Сарман үзәк район хастаханәсе» ДАССУ фельдшер-акушерлык пунктының шәфкать туташы (килештерү буенча) |
| 7 | Хокук бозулар һәм җинаятьләр өчен җаваплылык турында халыкка хәбәр итү, шул исәптән мәгълүмат стендлары аша | даими | Ләке авыл җирлеге җирле үзидарә органнары |
| 8 | Ел дәвамында авыл советы территориясендә җинаятьчелек дәрәҗәсен киметүне тәэмин итү буенча комплекслы оештыру чаралары үткәрү | даими | Ләке авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе, Россия Эчке эшләр министрлыгының Сарман районы буенча бүлегенең полиция участок уполномоченные (килештерү буенча) |
| 9 | Балигъ булмаган хокук бозучылар, социаль-куркыныч | даими | Ләке авыл җирлеге башкарма комитеты |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | хәлдә булган балалар, белем бирү учреждениеләренә йөрмәгән балалар, опекасыз һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар турында мәгълүмат җыюның, анализлауның һәм гомумиләштерүнең бердәм системасын формалаштыру. | | җитәкчесе, Башкарма комитет секретаре, Россия Эчке эшләр министрлыгының Сарман районы буенча бүлегенең полиция участок уполномоченные (килештерү буенча) |
| 10 | Авыл җирлеге башкарма комитеты утырышларында муниципаль берәмлектә җинаятьчелекне һәм хокук бозуларны профилактикалау мәсьәләләрен, шул исәптән хокук саклау органнары вәкилләрен карау | даими | Ләке авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе |
| 11 | Шәхесләр белән индивидуаль-профилактик һәм реабилитацион эшләр үткәрү:<br>- иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгәннәр;<br>- шартлы яки иректән мәхрүм итү белән бәйле булмаган җәза чараларына карата хөкем ителгәннәр;<br>- аларга карата иректән мәхрүм итүгә карата хөкем карарын үтәү кичектерелде;<br>- җәмәгать яисә административ йогынты чаралары куллану яисә амнистия акты аркасында җинаять җаваплылыгыннан азат ителгән җинаять кылучылар;<br>- җәмәгать яисә административ йогынты ясаучы хокук бозулар кылучылар;<br>- алкогольле һәм/яки спиртлы продукцияне чиктән тыш күп кулланучылар. | | Ләке авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе, Башкарма комитет секретаре, Россия Эчке эшләр министрлыгының Сарман районы буенча бүлегенең полиция участок уполномоченные (килештерү буенча) |
| 12 | Балалар җинаятьчелеген | даими | Ләке авыл җирлеге |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | профилактикалау мәсьәләләре буенча белем бирү учреждениеләрендә катнашу | | башкарма комитеты җитәкчесе |